Әхлак, тәрбия

# Тарихны барлау һәм олылау - изге гамәл



**8 сентябрьдә «Яктылык» мәктәбендә укучы балалар өчен тагын бер шатлыклы вакыйга булды. Танылган иганәче Гомәр әфәнде Батыршин алар өчен теплоходта Ширяево авылына сәяхәт оештырды. Чарада укытучылар, төрле татар оешмаларының хезмәткәрләре, тарихчы-язучылар катнаштылар. Иң элек мөфти Талип хәзрәт Яруллин барыбызга да уңышлы сәяхәт теләп дога кылды. Самара Җәмигъ мәчете имамы Иршат хәзрәт Сафин Ширяево авылында тарихыбыз һәм Ислам дине турында кызыклы чыгыш ясады.**

**Укытучылар, татар җәмгыятьләренең җитәкчеләре, журналистлар, дин әһелләре, газеталар һәм интернет-сайтларның хезмәткәрләре, балаларның ата-аналары - барысы да бу очрашудан күп кенә кызыклы һәм файдалы мәгълүматлар алдылар. Кайберәүләр әле беренче мәртәбә биредә чал Иделнең даһи гүзәллеген күрделәр һәм гасырлар буенча караваннар йөргән зур елганы бөек Болгар бабаларыбызның үз кулларында тотулары турында ишеттеләр. Бу изге сәяхәт белем туплау, дуслашу, берләшү, күмәк планнар кору һәм, әлбәттә, үтемле тәрбия чарасы да булды.**

**Элегрәк дин әһелләре, мәктәп балалары, укытучылар һәм эшмәкәрләр арасында ниндидер читсенү, ятсыну кебек нәрсәләр булса, бу сәяхәттә алар арасында дуслык, бер-берсенә ихтирам сизелде.**

**Бу сәфәр - ул гади, күңел ачу чарасы гына түгел. Биредә һәркемдә, бигрәк тә балаларда, бай тарихыбызга олы хөрмәт һәм горурлык хисләре тәрбияләнде. Алар күңелендә бик күп кызыклы мәгълүматлар һәм хисләр тупланды.**

**Монда ясалган чыгышларда, милләтебез һәм телебез киләчәген кайгырту белән бергә, балаларга әхлакый тәрбия бирү хакында һәм башка төрле актуаль мәсьәләләр кузгатылды. Бу сәяхәтне оештыручы һәм анда чыгыш ясаучы, төрле сорауларга җавап бирүче милләтпәрвәрләр, дин әһелләре һәм алар тарафыннан әйтелгән фикерләр турында газета укучыларыбызга да кыскача хәбәр бирәбез.**

***Гомәр Мулланур улы Батыршин,*** эшкуар, иганәче. Ул «Булгарское наследие» исемле фонд оештырды. Бу фондның төп максаты - чынбарлык тарихыбызны, кимсетелгән динебезне, милли рухыбызны торгызу һәм үстерү. Гомәр әфәнде - аз сөйли, ләкин зур эшләр башкара торган шәхес. Аның эшчәнлеге киңкырлы: диннне үстерү юлында мәчет төзеде, данлыклы тарихыбызны пропагандалау юлында эчтәлекле, матур итеп эшләнгән китап бастырды. Меңнәрчә еллар буена төрки халыклар үсешенең ышанычлы бишеге һәм Болгар дәүләтенең чик сакчысы булган Самара Җәясендә һәйкәл куйдырды. Ул һәйкәл - Идел Болгарстанының дәүләтчелек билгесе. Болар әлегә кадәр татар халкына карата: «Сез Чыңгызханга ияреп килгән кансыз һәм кыргый халыкның токымы», - дигән мыскыллауларны себереп түгәләр.

Бүген без Европа һәм Азия илләренә уңай тормыш үрнәге биргән болгарларның: «Алар безнең данлыклы бабаларыбыз булганнар»! - дип горурлана алабыз.

Һәр исемнең төбендә тирән мәгънә ята. Гомәр - ул гомер, яшәү, дигән мәгънәдә. Ә Батырша - ул инде сүз сезгә аңлашыла.

Гомәр әфәнде - үз гомерен халкыбызга зур хезмәт күрсәтеп яшәүче, батыр йөрәкле һәм киң күңелле шәхес.

**Ильяс Шәкүров** - фәннәр докторы, «ИПОЗЕМбанк»ның директорлар советы рәисе, «Туган тел» исемле Самара өлкә татар җәмгыяте президенты һәм «Яктылык» мәктәбенең Попечительләр советы җитәкчесе, Самара өлкәсендәге «Эшкуарлык үсешенә ярдәм итү» фонды җитәкчесе. Ул яшьләрнең милләтне, телне үстерү буенча башкарган эшләренә төрле грантлар, призлар әзерли, сабантуйлар, төрле милли-мәдәни чаралар уздырганда матди ярдәм күрсәтеп тора.

Ильяс әфәнде бу очрашуны бер табигый конференция рәвешендә алып барды.

***Рифкать Туктар улы Хуҗин:***

Ул Самара шәһәренең татар милли-мәдәни мохтариятен җитәкли. «Сөмбелә» һәм «Балалар фестивале» кебек бәйрәмнәр үткәрүне һәрвакыт тулысынча үз өстенә ала. Башка бәйрәмнәрне оештыруда да күп булышлык күрсәтә.

***Шамил Хәйдәр улы Галимов*** - «Азан» газетасы мөхәррире.

Ул төбәгебез тарихын ачыклау буенча эш алып бара. Биш китап бастырып чыгарды. Шамил Галимов хәзерге көндәге мәчетләр тарихы, дин әһелләренең язмышы турында сөйләде.

Быел Самара шәһәрендә «Булгарская цивилизация на Волге» исемле китап басылып чыкты. Ул эчтәлекле, гади



Иганәче Гомәр Батыршин һәм «Яктылык» мәктәбе директоры Радик Газизов

тел белән язылган һәм сирәк очрый торган кыйммәтле вакыйгаларга бай. Аның беренче өлешендә Казан галимнәре Гамирҗан Дәүләтшин һәм Фаяз Хуҗин язган тарихи мәгълүматлар кыскартылып, укырга һәм аңларга яраклаштырып, эшкәртелеп бастырылды. Китапның авторы - Фәрид Шириязданов. Икенче өлешендә аның тирән эзләнүләре нәтиҗәсендә бай мәгълүмат тупланган.

Сәяхәттә катнашкан барлык кешегә дә бу китаплар бүләк итеп таратылды. Алар әле тарихыбызга, милләтебезгә карата киләчәктә дә күпләрдә тирән ихтирам һәм горурлык хисләре уятырлар, дип ышанасы килә.

Бу сәяхәттән нинди нәтиҗәләр ясап була соң? Ул балаларны укудан калдыру һәм күңел ачу чарасы гына булып калмадымы?

Моның әһәмиятен һәм үзкыйммәтен, әлбәттә, бәяләп бетерерлек түгел. **Бу туган җиребезгә, илебезгә, милләтебезгә һәм чынбарлык тарихыбызга олы хөрмәт тәрбияләү чарасы һәм нәтиҗәле табигый дәрес булды.** Киләчәктә мондый сәяхәтләр әле тагын да файдалырак, кызыклырак булыр, дип ышанасы килә.

Газетабызның соңгы басмаларында без «Яктылык» мәктәбендәге Ислам491 динен ә карата уңай караш көчәюен белдереп торабыз. Киләчәктә Самара өлкәсе Диния нәзарәте белән «Яктылык» мәктәбе арасында бәйләнеш ныгыса, яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә уңышлар һәрвакыт үсеш юлында булырлар, дигән өмет бар.

Аңлатма:

**Сәяхәтнең ахыргы чиге Ширяево поселогы булды. Анда Идел ярының биек җиренә һәйкәл куелган. Аның югары өлешендә барс сурәте. Бу - Идел Болгарстаны дәүләтчелегенең билгесе. Ә ул нәрсәне аңлата соң? Болгар милләте бик күп ырулардан, кабиләләрдән торган төрки халыкларның берләшмәсе булган. Аларның һәрберсенең үз гаскәре, үз җирләре булган, ә башлыклары хан җитәкләгән советка кергәннәр. Ярымбәйсез ыруларның төрле тамгалар, сурәтләр төшерелгән байраклары булган, ә берсиллар байрагында - барс сурәте. Алар болгар халкын берләштереп тотучы иң затлы, данлыклы нәсел дип саналганнар. (Барил - барс иле халкы). Алар җитез, кыю, көчле һәм курку белмәс токым булганга, үзләрен барс кебек гайрәтле итеп хис иткәннәр. Барсиллар нәселе, гадәттә, башкалада һәм стратегик яктан әһәмиятле җирдә яшәгән.**

***Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.***